ГЛАВА НУРИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НӨНӘГӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

«28» сентябрь 2022 ел — №4

## Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Чутай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге Уставының 23.1.статьсы һәм «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында» 2019 елның 27 октябрендәге 120 номерлы карар белән расланган Нигезләмә, «Гражданнар җыенын уздыруны инициативалау турында» 2021 елның 27 октябрендәге 9 номерлы карар нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Ненәгәр авыл җирлеге башлыгы

Карар чыгарды:

1. Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлегенең Чутай авылында үзара салымны куллану мәсьәләсе буенча 2022 елның 10 сентябрендә 15 сәгать 00 минутка гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Җыен үткәрү урыны итеп Татарстан Республикасы, Балтач районы, Чутай авылы, Салих Сәйдәшев урамы, 50 нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йортын билгеләргә.

3. Балтач муниципаль районы Нөнәгәр авыл җирлеге башкарма комитетына:

- сайлау хокукы булган Чутай авылы халкы исемлеген тезергә;
- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;
- гражданнар җыенын үткәрү турында халыкка хәбәр итү.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез материаллар сатып алу һәм зират коймасын ремонтлау өчен җыелган үзара салым акчаларын шулай ук Чутай авылы зираты коймасын ремонтлау өчен зиратны агач һәм куаклардан чистартуга юнәлтергә ризамы;

ӘЙЕ — ЮК».

5. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә авыл җирлеге мәгълүмат стендларына, Балтач муниципаль районының рәсми сайтына baltasi.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы: А. З. Әхмәтханов